**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

13 декабрь 2019 № 326

**Финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнешкә ия субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) булган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертларны бирү Кагыйдәләре турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142 статьясы нигезендә, Биектау муниципаль районы Советы,

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Теркәлгән финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнешкә ия субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) булган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертларны бирү Кагыйдәләрен расларга.

2. Әлеге карарның нигезләмәләре Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр порталында Биектау муниципаль районы Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб адресы буенча басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән соң) үзенең законлы көченә керә һәм 2020 елга бюджет һәм планлы чорга 2021 һәм 2022 елларга Биектау муниципаль районы бюджетын төзегәндә һәм башкарганда килеп туган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

3. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб адресы һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Советының бюджет, финанслар һәм икътисади сәясәт буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
муниципаль районы Башлыгы Р.Г. Кәлимуллин

Кушымта

Расланган
Биектау муниципаль районы
Советы карары белән
13/VI 2019 № 326

# Финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнешкә ия субсидияләр (башка бюджетара трансфертлар) булган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертларны бирү Кагыйдәләре

1. Әлеге Кагыйдәләр Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертларны бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын билгелиләр (алга таба – башка бюджетара трансфертлар).

2. Башка бюджетара трансфертлар чыгым йөкләмәләрен башкару максатларында биреләләр.

3. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетында билгеле финанс елына һәм планлы чорга күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре һәм чыгым йөкләмәләре нигезендә күздә тотылган максатларга Башкарма комитетка билгеләнгән тәртиптә илтеп җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә биреләләр.

4. Башка бюджетара трансфертлар, билгеләнгән критерияләргә җавап бирүче авыл җирлекләре бюджетларына биреләләр.

5. Башка бюджетара трансфертлар бирү һәм тотуның шартлары булып торалар:

а) башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешүне әлеге Кагыйдәнең 13 пункты нигезендә төзү;

б) авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясы белән күздә тотылган, башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын тоту.

6. Башка бюджетара трансфертлар алу өчен Биектау муниципаль районы авыл җирлеге башкарма комитеты (алга таба – вәкаләтле орган), Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән срокларда, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан расланган форма буенча башка бюджетара трансфертлар бирү турында гариза бирә.

7. Авыл җирлеге бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме, билгеләнгән тәртиптә формула буенча исәпләнә.

8. Башка бюджетара трансфертларны җирлек бюджетлары арасында бүлү Башкарма комитетның муниципаль хокукый акты тарафыннан раслана.

9. Башка бюджетара трансфертларны бирү, Башкарма комитет һәм вәкаләтле орган арасында төзелә торган башка бюджетара трансфертларны бирү турында килешү нигезендә, Башкарма комитет раслаган форма нигезендә тормышка ашырыла.

10. Килешүдә күздә тотылалар:

башка бюджетара трансфертларның күләме, аларның максатчан кулланылышы;

башка бюджетара трансфертларны бирүнең нәтиҗәлелеге күрсәткечләре;

башка бюджетара трансфертларны күчерү тәртибе;

башка бюджетара трансфертларны куллану турында хисап тәкъдим итү сроклары һәм формалары һәм башка бюджетара трансфертларны бирүнең нәтиҗәлелелек күрсәткечләренә ирешү;

башка бюджетара трансфертларны алучы тарафыннан башка бюджетара трансфертларның билгеләнгән куллану нәтиҗәлелеге күрсәткеченә җитмәве нәтиҗәсе;

башка бюджетара трансфертларны алучы тарафыннан килешү белән күздә тотылган йөкләмәләрне тотуның контролен тормышка ашыру тәртибе;

якларның килешү шартларын бозган өчен җаваплылыгы.

11. Башка бюджетара трансфертларны куллануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре булып торалар:

- бюджет турында карар нигезендә чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елы һәм планлы чор) беркетелгән керем чыганаклары һәм муниципаль район бюджетыннан башка бюджетара трансфертларның җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен чыгымнарның кирәкле күләменә чагыштырмасы 100 проценттан ким булган җирлекләр саны;

- башка бюджетара трансфертларны бирү елында бюджетны башкару процессында муниципаль бурыч алуларны башка бюджетара трансфертларны бирү ел чигеннән чыгып тормышка ашырмый торган җирлекләр саны.

Нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешүгә бәя Башкарма комитет тарафыннан вәкаләтле орган тәкъдим иткән хисапка уздырылган анализ нигезендә тормышка ашырыла.

12. Вәкаләтле органнар Башкарма комитетка башка бюджетара трансфертларны куллану турында хисапны килешү белән күздә тотылган тәртиптә һәм форма буенча тәкъдим итәләр.

13. Башкарма комитетка бирелә торган мәгълүматларның дөреслеге өчен җаваплылык вәкаләтле органга йөкләнә.

14. Башка бюджетара трансфертлар “Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы” МКУ тарафыннан җирлек бюджетларына, җирле бюджетларны башкаруны касса тәэмин итүе өчен ачылган Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсе территориаль органы счетларына, килешү белән күздә тотылган срокларда күчерелә.

15. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын бозган очракта, билгеле акчалар муниципаль район бюджеты кеременә, Россия Федерациясе бюджет законнары белән билгеләнгән тәртиптә күчерелергә тиеш.

16. Башка бюджетара трансфертлар бирү елыннан соң килүче елның 1 нче гыйнварына кулланылмаган башка бюджетара трансфертларның калган өлеше,

Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән билгеләнгән таләпләр нигезендә муниципаль район бюджеты керемена кире кайтарылырга тиеш.

17. Башка бюджетара трансфертлар максатчан характерга ия һәм әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатлардан кала башка максатларда куллана алмый.

18. Башка бюджетара трансфертларны максатчан куллануны контрольдә тоту, законнар нигезендә Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты һәм "Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы" МКУ тарафыннан тормышка ашырыла.